ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 июля 2019 ел № 3337

Яр Чаллы шәһәре рәсми сайтының http://nabchelny.ru конфиденциальлек сәясәтен раслау турында

Яр Чаллы шәһәре рәсми сайтыннан файдаланучыларның персональ мәгълүматларын эшкәртү процессын җайга салу максатында «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр турында һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ санлы Федераль закон, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ санлы федераль закон, шәһәр Уставының 53 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре рәсми сайтының http://nabchelny.ru конфиденциальлек сәясәтен кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 1 июлендәге
3337 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре
рәсми сайтының http://nabchelny.ru
конфиденциальлек сәясәте

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Персональ мәгълүматларның конфиденциальлек сәясәте (алга таба – Конфиденциальлек сәясәте) Яр Чаллы шәһәре рәсми сайты http://nabchelny.ru (алга таба – Сайт) сайттан файдаланган вакытта Файдаланучы турында алырга мөмкин булган барлык мәгълүматка кагыла.

2. Әлеге Конфиденциальлек сәясәтендә «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә төшенчәләр, шулай ук түбәндәге билгеләмәләр кулланыла:

1) Сайт администраторы – Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты муниципаль казна учреждениесе исеменнән эш йөртүче, персональ мәгълүматларны эшкәртүне оештыра һәм (яки) гамәлгә ашыра торган, шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртү максатларын, эшкәртелергә тиешле персональ мәгълүматлар составын, персональ мәгълүматлар белән башкарыла торган гамәлләрне (операцияләрне) билгели торган Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының Сайтны (конфиденциальлек сәясәтенә 1 нче кушымта) алып бару өчен җаваплы хезмәткәрләре;

2) персональ мәгълүматларның конфиденциальлеге – оператор яки персональ мәгълүматка рөхсәт алган башка зат тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булган, аларны персональ мәгълүматлар субъекты ризалыгыннан башка таратуга яки башка законлы нигез булуга юл куймау таләбе;

3) Сайттан файдаланучы (алга таба – Файдаланучы) – Интернет челтәре аша Сайтка керү мөмкинлеге булган һәм Сайттан файдаланучы зат;

4) Cookies – тиешле сайт битен ачарга ниятләгәндә HTTP-запроста һәрвакыт веб-клиент яки веб-браузер тарафыннан веб-серверга җибәрелгән һәм веб-сервер тарафыннан җибәрелеп, файдаланучының компьютерында саклана торган мәгълүматларның зур булмаган фрагменты;

5) IP-адрес — IP беркетмәсе буенча төзелгән компьютер челтәрендәге узелның уникаль челтәр адресы.

3. Файдаланучы тарафыннан Сайттан файдалану әлеге Конфиденциальлек сәясәте һәм Файдаланучының персональ мәгълүматларын эшкәртү шартлары белән килешүен аңлата.

4. Конфиденциальлек сәясәтенең шартлары белән килешмәгән очракта Файдаланучы Сайттан файдалануны туктатырга тиеш.

5. Әлеге Конфиденциальлек сәясәте бары тик Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтына http://nabchelny.ru карата гына кулланыла.

6. Сайт администраторы Сайттан файдаланучы бирә торган персональ мәгълүматларның дөреслеген тикшерми.

7. Әлеге Конфиденциальлек сәясәте, сайтта теркәлгәндә Сайт администраторының запросы буенча Файдаланучы бирә торган персональ мәгълүматлар конфиденциальлеген саклау режимын тәэмин итү һәм таратмау буенча Сайт администраторы йөкләмәләрен билгели.

## 2 бүлек. Файдаланучының персональ мәгълүматларын эшкәртү максатлары

8. Персональ мәгълүматларны җыйганда Администраторның төп максаты – Файдаланучыларга мәгълүмати хезмәт күрсәтү.

9. Файдаланучының персональ мәгълүматларын Сайт администраторы түбәндәге максатларда файдалана ала:

1) сайтка теркәлгән Файдаланучыны идентификацияләү;

2) Файдаланучыга сайтның персональ ресурсларына керү мөмкинлеген бирү;

3) Файдаланучы белән кире элемтә билгеләү, шул исәптән Сайттан файдалануга, хезмәт күрсәтүгә, Файдаланучының запросларын һәм гаризаларын эшкәртүгә кагылышлы белдерүләр, запрослар җибәрү;

4) иминлекне тәэмин итү, мошенниклыкны булдырмау өчен Файдаланучының урнашу урынын билгеләү;

5) Файдаланучы тарафыннан бирелгән персональ мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын раслау;

6) статистик хисаплылыкны формалаштыру һәм иясез мәгълүматлар нигезендә башка тикшеренүләр уздыру.

## 3бүлек. Файдаланучыларның персональ мәгълүматын эшкәртү шартлары һәм ысуллары, аны өченче затларга тапшыру

10. Әлеге Конфиденциальлек сәясәте кысаларында эшкәртүгә рөхсәт ителгән персональ мәгълүматлар Файдаланучы тарафыннан сайттагы теркәү формасын тутыру юлы белән бирелә һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

1) Файдаланучының фамилиясе, исеме, атасының исеме;

2) электрон почта адресы (e-mail).

11. Cookies өзү авторизацияне таләп итә торган сайт бүлекләренә керү мөмкинлеге булмауга китерергә мөмкин.

12. Сайт үзенә керүчеләрнең IP-адреслары турында статистика җыюны гамәлгә ашыра. Әлеге мәгълүмат техник проблемаларны ачыклау һәм хәл итү максатында кулланыла.

13. Югарыда искәртелмәгән теләсә кайсы башка персональ мәгълүмат (кулланыла торган браузерлар һәм операцион системалар һ.б.), әлеге Конфиденциальлек сәясәтенең 15 һәм 16 пунктларында каралган очраклардан тыш, ышанычлы рәвештә сакланырга һәм таратылмаска тиеш.

14. Файдаланучының персональ мәгълүматларын эшкәртү, теләсә кайсы законлы ысул белән, шул исәптән автоматизация чараларын кулланып яки мондый чараларны кулланмыйча, мәгълүмати персональ мәгълүматлар системаларында срогы чикләнмәгән вакытта гамәлгә ашырыла.

15. Файдаланучының персональ мәгълүматлары Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән нигезләр һәм тәртиптә генә Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына тапшырылырга мөмкин.

16. Сайт администраторы персональ мәгълүматларны югалткан яки тараткан очракта, персональ мәгълүматларны югалту яки тарату турында Файдаланучыга хәбәр итә.

17. Сайт администраторы Файдаланучының персональ мәгълүматын хокуксыз яки очраклы керүдән, юк итүдән, үзгәртүдән, блокировкалаудан, күчереп алудан, таратудан, шулай ук өченче затларның башка хокуксыз гамәлләреннән саклау өчен кирәкле оештыру һәм техник чаралар күрә.

## 4 бүлек. Якларның бурычлары

18. Файдаланучы бурычлы:

1) Сайттан файдалану өчен кирәкле персональ мәгълүматлар турында мәгълүмат бирергә;

2) бирелгән персональ мәгълүматлар үзгәргән очракта, мондый мәгълүматны яңартырга, өстәмәләр кертергә.

19. Файдаланучы Сайт битләренә һәм бүлекләренә кереп, шулай ук мәгълүматларны кертү формаларын тутырып, үзенең әлеге Конфиденциальлек сәясәте һәм анда күрсәтелгән шартлар, аның персональ мәгълүматларын эшкәртү максатлары белән ризалыгын белдерә. Әлеге шартлар һәм персональ мәгълүматларны эшкәртү максатлары белән килешмәгән очракта, Файдаланучы сайттан файдаланудан тыелырга тиеш.

20. Файдаланучы әлеге мәгълүматны тапшыру формалары ярдәмендә бирелгән мәгълүматның тулы, төгәл һәм дөрес булуын гарантияли; ул РФ гамәлдәге законнарын, өченче затларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозмый һәм шәхсән үзенә карата тутырылган.

21. Сайт администраторы бурычлы:

1) алынган мәгълүматны бары тик әлеге Конфиденциальлек сәясәтенең 2 бүлегендә күрсәтелгән максатлар өчен генә файдаланырга;

2) конфиденциаль мәгълүматны сер итеп саклауны тәэмин итәргә, Файдаланучының алдан язма рөхсәтеннән башка таратырга, шулай ук, әлеге Конфиденциальлек сәясәтенең 15 һәм 16 пунктларыннан тыш, Файдаланучының бирелгән персональ мәгълүматларын башка мөмкин ысуллар белән сатуны, алмаштыруны, бастырып чыгаруны яки таратуны гамәлгә ашырмаска.

3) Файдаланучының персональ мәгълүматлары конфиденциальлеген яклау өчен, гамәлдәге эшлекле әйләнештә мондый төрдәге мәгълүматны саклау өчен кулланыла торган тәртип буенча чаралар күрергә.

22. Дөрес булмаган персональ мәгълүматлар яки хокуксыз гамәлләр ачыкланган очракта, Файдаланучы яки аның законлы вәкиле яисә персональ мәгълүматлар субъектларының хокукларын яклау буенча вәкаләтле орган

мөрәҗәгать иткән яки запрос ясаган вакыттан башлап, тикшерү чорына тиешле Файдаланучыга кагылышлы персональ мәгълүматларны блокировкалауны гамәлгә ашырырга.

5 бүлек. Якларның җаваплылыгы

23. Үз бурычларын үтәмәгән Сайт администраторы, әлеге Конфиденциальлек сәясәтенең 15, 16 һәм 24 пунктларында каралган очраклардан тыш, Россия Федерациясе законнары нигезендә, персональ мәгълүматларны хокуксыз файдалануга бәйле рәвештә Файдаланучы тарафыннан китерелгән зыян өчен җаваплы.

24. Конфиденциаль мәгълүматны югалткан яки тараткан очракта Сайт администраторы җаваплы түгел, әгәр әлеге конфиденциаль мәгълүмат:

1) аны югалтканга яки тараткангa кадәр халык мөлкәте булса;

2) Сайтның администраторы аны алган вакытка кадәр ул өченче яктан алынган булса;

3) Файдаланучының ризалыгы буенча таратылган булса.

6 бүлек. Бәхәсләрне хәл итү

25. Сайттан Файдаланучы һәм сайт администраторы арасындагы мөнәсәбәтләрдән килеп чыккан бәхәсләр буенча дәгъва белән судка мөрәҗәгать иткәнче претензия (бәхәсне ирекле җайга салу турында язма тәкъдимнәр) бирү мәҗбүри булып тора.

26. Претензияне алучы претензияне алган көннән соң 30 календарь көн эчендә гариза бирүчегә претензияне карап тикшерү нәтиҗәләре турында язмача хәбәр итә.

27. Килешенүгә ирешеп булмаган очракта, бәхәс Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә суд органына карап тикшерүгә тапшырылачак.

28. Әлеге Конфиденциальлек сәясәтенә һәм Файдаланучы белән Сайт администраторы арасындагы мөнәсәбәтләргә карата Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары кулланыла.

7 бүлек. Өстәмә шартлар

29. Әлеге Конфиденциальлек сәясәте Башкарма комитет карары белән раслана һәм яңа Конфиденциальлек сәясәте расланганчы гамәлдә була.

30. Сайт администраторы Файдаланучының ризалыгыннан башка әлеге Конфиденциальлек сәясәтенә үзгәрешләр кертергә хокуклы.

31. Мондый үзгәрешләр кертелгәннән соң Сайттан файдалануны дәвам итү, Файдаланучының мондый үзгәрешләр белән ризалыгын раслый.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова